КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 октябрь

г.Казань

№ 894

2020 елда идарәче компанияләргә һәм (яисә) сәнәгать (индустриаль) парклар, сәнәгать мәйданчыклары резидентларына аларның инфраструктурасын үстерүгә займнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру өчен "Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2020 елда идарәче компанияләргә һәм (яисә) сәнәгать (индустриаль) парклар, сәнәгать мәйданчыклары резидентларына аларның инфраструктурасын үстерүгә займнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру өчен "Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенә субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар
Кабинетының 2020 ел, 2
октябрь, 894 нче карары
белән расланды

2020 елда идарәче компанияләргә һәм (яисә) сәнәгать (индустриаль) парклар, сәнәгать мәйданчыклары резидентларына аларның инфраструктурасын үстерүгә займнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру өчен "Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенә субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән раслан «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады" дәүләт программасының (алга таба - дәүләт программасы) «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының «Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарәче компанияләренә һәм резидентларына, аларның инфраструктурасын үстерүгә займнар бирү рәвешендә ярдәм күрсәтү» чарасын гамәлгә ашыруга бәйле «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе (алга таба – Фонд) чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү механизмын билгели.

Субсидияләр идарәче компанияләргә һәм (яки) сәнәгать (индустриаль) парклар, сәнәгать мәйданчыклары резидентларына аларның инфраструктурасын үстерүгә займнар бирү максатларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә (алга таба – субсидия).

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп терминнар һәм төшенчәләр:

бюджет акчаларын баш бүлүче – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

займ – сәнәгать (индустриаль) парклар, сәнәгать мәйданчыклары инфраструктурасын үстерү максатларында, Фонд тарафыннан идарәче компанияләргә һәм (яки) резидентларга еллык биш процент белән бирелә, беренче 12 айга төп бурычны түләүдән азат итү шартларында, бер идарәче компаниягә һәм (яки) бер резидентка 30 000 сум күләмендә12 айдан алып 60 айга кадәр срокка бирелә торган акча;

сәнәгать (индустриаль) паркы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында" 2014 ел, 27 август, 616 нче карары белән билгеләнгән мәгънәдә кулланыла торган сәнәгать

(индустриаль) паркы;

сәнәгать мәйданчыгы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында" 2014 ел, 27 август, 616 нче карары белән билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла торган сәнәгать мәйданчыгы, «сәнәгать мәйданчыгы» һәм «төзелә торган (проектлана торган) сәнәгать мәйданчыгы»;

резидент – Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән һәм сәнәгать (индустриаль) паркы, сәнәгать мәйданчыгы территориясендә тиешле идарәче компания белән төзелгән шартнамә нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик зат яисә шәхси эшмәкәр;

сәнәгать (индустриаль) парклары, сәнәгать мәйданчыклары инфраструктурасын үстерү – коммуналь һәм юл инфраструктурасы объектларын, сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының биналарын, корылмаларын, төзелмәләрен булдыру, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү;

коммуналь инфраструктура – сәнәгать (индустриаль) парклары, сәнәгать мәйданчыклары территорияләрендә урнашкан һәм резидентлар эшчәнлеген тәэмин итә торган электр, газ, җылылык, җылылык, су белән тәэмин итү, электр энергетикасы өлкәсендә товарлар китерү һәм хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән объектлар комплексы;

юл инфраструктурасы – сәнәгать (индустриаль) парклары, сәнәгать мәйданчыклары территорияләрендә урнашкан һәм резидентлар эшчәнлеген тәэмин итә торган автомобиль һәм (яки) тимер юллар;

идарәче компания – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында" 2014 ел, 27 август, 616 нче карары белән билгеләнгән мәгънәдә кулланыла торган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында" 2014 ел, 27 август, 616 нче карары нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән аккредитация турында гамәлдәге таныклыгв булган идарәче компания.

3. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчаларын баш бүлүчегә кадәр бюджет акчаларын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидияләр бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү планлаштырыла торган айның беренче көнендә Фонд туры килергә тиеш булган таләпләр:

субсидия алучы салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләргә ия түгел;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән (җайга салынмаган) бүтән бурычлары юк;

үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, аңарга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылып тормый;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында квалификацияле җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки Фондның баш бухгалтеры турында мәгълүматлар юк;

Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә акча алырга тиеш түгел.

5. Субсидия алу өчен Фонд бюджет акчаларын баш бүлүчегә түбәндәге документлар тапшыра:

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча гариза;

гамәлгә кую документларының күчермәләре;

агымдагы финанс елына һәм план чорына Фондның Фонд Советы тарафыннан хупланган үсеш концепциясе;

Фондның әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар;

идарәче компанияләргә һәм (яки) резидентларга займнар бирү шартларын раслау турында Фонд Советы беркетмәсе;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә сәнәгать (индустриаль) парклары, сәнәгать мәйданчыклары Идарәче компанияләреннән һәм (яки) резидентларыннан мөрәҗәгатьләр реестры;

Фонд үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик зат буларак дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе (юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсе);

фондны салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә

Фонд тарафыннан әлеге пунктның тугызынчы – унберенче абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, бюджет акчаларын баш бүлүче күрсәтелгән документларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

6. Гариза кабул ителгән көнне бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан гаризалар теркәү журналына теркәлә, ул сан сугылган, беркетелгән һәм мөһер белән таныкланган булырга тиеш. Бюджет акчаларын баш бүлүче гариза теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә, аны әлеге Тәртип таләпләренә туры килүен тикшерә һәм субсидия бирү яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

Фонд тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 5 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

Фондның әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

Фонд тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

8. Бюджет акчаларын баш бүлүче Фондка субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турындагы карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү хакында хәбәр итә.

9. Субсидия бирү бюджет акчаларын баш бүлүче белән Фонд арасында төзелгән килешү нигезендә, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типик форма нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре, аны Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү шартлары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

субсидияне күчерү сроклары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында Фонд тарафыннан хисап бирү сроклары һәм формасы, шулай ук өстәмә хисап бирү (кирәк булганда);

субсидияне биргәндә билгеләнгән шартларны бозган очракта субсидияне кире кайтару очраклары;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган калган субсидияләрне (финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган Фондның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелә торган субсидияләрдән тыш) кире кайтару очраклары, әгәр бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан агымдагы финанс елында субсидия бирү максатларында бу акчалардан файдалану турында карар кабул ителмәсә;

штраф санкцияләрен куллану очраклары һәм тәртибе;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тотучы шарт, бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан аларны куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә;

субсидия акчсы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш;

займ акчаларының максатчан кулланылышын контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда Фондның бурычы;

фондның займчылардан акчаларны тулы күләмдә кайтаруны тәэмин итү бурычы;

Фонд тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган Килешү шартларын үтәү турында нигезләмә;

килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән займ шартнамәләре буенча займ алучылар булган Фонд һәм идарәче компанияләр һәм (яки) резидентларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне дәүләт

финанс тикшерүе органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга ризалыгы.

Кирәк булганда, бюджет акчаларын баш бүлүче Фонд белән Килешүне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә өзү турында өстәмә килешү төзи.

10. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып 2020 елда идарәче компанияләргә һәм (яки) резидентларга коммуналь һәм юл инфраструктурасы объектларын , сәнәгать (индустриаль) парклары, сәнәгать мәйданчыкларының биналарын, корылмаларын, төзелмәләрен төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү өчен Килешүдә билгеләнгән күләмдә займнар бирү тора.

11. Субсидия Фондка әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 200 000 сум күләмендә бирелә.

12. Бюджет акчаларын баш бүлүче Фондның Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына, Килешү төзелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә күчерә.

13. Фонд бюджет акчаларын баш бүлүчегә субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча түбәндәге хисапларны тапшыра:

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында хисап, займ шартнамәләренең һәм займ күчерү турында түләү йөкләмәләренең расланган күчермәләрен кушып, әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә форма буенча;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап.

14. Субсидия Фонд тарафыннан бюджет акчаларын баш бүлүченең тиешле таләбе алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

бюджет акчаларын баш бүлүче һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу фактларын ачыклау;

субсидия алу өчен Фонд тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында , субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисапларны, өстәмә хисапны Фонд тарафыннан тапшырмау (әгәр дә ул Килешүдә каралган булса);

Фонд тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәү;

Фонд тарафыннан субсидия чараларын максатсыз куллану.

Әгәр Фонд тарафыннан Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелмәгән булса, бюджет акчаларын баш бүлүче әлеге карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә мәҗбүри хәбәр итеп, Фондка карата штраф санкцияләрен куллану турында карар кабул итә.

Күрсәтелгән очракта штраф санкцияләре (А) күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$A = \left(1 - \frac{d}{D}\right) \times X \times V,$$

монда:

d - субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсе;

D – Килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенең пландагы әһәмияте;

X – хисап чорының соңгы көненә торышы буенча Россия Федерациясе Үзәк банкының өч йөзлек төп ставкасының берсенә тигез корректлау коэффициенты;

V – Фонд тарафыннан алынган субсидия акчалары күләме.

15. Хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләр калдыклары агымдагы финанс елында бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан күрсәтелгән акчаларга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта кулланылырга мөмкин, шул ук вакытта нәтиҗәгә ирешү, штраф санкцияләрен кулланмыйча, киләсе елга күчерелә.

Бюджет акчаларын баш бүлүченең хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләр калдыкларына ихтыяҗ булу турында карары булмаганда, күрсәтелгән акчалар хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

16. Әлеге Тәртипнең 14, 15 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне, субсидия калдыкларын Фонд тарафыннан кире кайтару сроклары бозылганда, бюджет акчаларын баш бүлүче, эш көннәрендә исәпләнелгән җиде көн эчендә, Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, субсидия калдыкларын мәҗбүри тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

17. Бюджет акчаларын баш бүлүче һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары Фондка субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең әлеге Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыралар.